КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям**
420097, г. Казань, ул. Академическая, 2
Тел.: (843) 570-31-22, 537-91-02, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.com
e-mail: reception@tatmedia.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
420097, Казан ш., Академия ур., 2
Тел.: (843) 570-31-22, 537-91-02, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.com
e-mail: reception@tatmedia.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

2013 елның 15 августы, № 13-п/1

Дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупиягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ТРЗ номерлы Федераль законны, «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указын һәм «Гражданнар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре аларны биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге 701-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указын үтәү максатыннан **боерык бирәм**:

1. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында гражданнар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре аларны биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән граждан дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң, әгәр әлеге оешмага дәүләт идарәсенең (административ идарәнең) аерым функцияләре дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи

(хезмəттəге) бурычларына керə торган булса, дəүлəт хезмəткəрлəренең хезмəттəге үз-үзен тотышына талəплəрне үтəү һəм мəнфəгатьлəр ихтыяҗын җайга салу буенча тиешле комиссия ризалыгы белəн, ике ел дəвамында оешмада хезмəт шартнамəсе нигезендə вазыйфа билəү һəм (яисə) бу оешмада ай дəвамында граждан-хокук шартнамəсе (граждан-хокук шартнамəлəре) нигезендə йөз мең сумнан артыграк эш башкару (əлеге оешмада хезмəт күрсəтү) хокукына ия.

2.2. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендə билгелəнə торган исемлеккə кертелгəн дəүлəт хезмəте вазыйфасын билəгəн граждан, дəүлəт хезмəтеннəн киткəннəн соң ике ел дəвамында əлеге пунктның 2.1. пунктчасында күрсəтелгəн эшлəр башкаруга (хезмəтлəр күрсəтүгə) хезмəт шартнамəсе яисə граждан-хокук шартнамəлəре төзегəндə, үзенең соңгы хезмəт урыны турында белешмəлəрне эш бирүчегə хəбəр итəргə тиеш.

2.3. Исемлеккə кертелгəн дəүлəт хезмəте вазыйфаларын билəгəн гражданның дəүлəт хезмəтеннəн киткəннəн соң əлеге пунктның 2.2. пунктчасында каралган талəплəрне үтəмəве əлеге граждан белəн бу пунктның 2.1. пунктчасында күрсəтелгəн эшлəр башкаруга (хезмəтлəр күрсəтүгə) хезмəт шартнамəсенең яисə граждан-хокук шартнамəсенең туктатылуына китерə.

3. «Татмедиа» республика матбугат һəм массакүлəм коммуникациялəр агентлыгының кадрлар бүлеге башлыгына:

- Исемлеккə кертелгəн вазыйфаларны билəүче дəүлəт граждан хезмəткəрлəрен əлеге боерык белəн таныштырырга;

- Исемлекне, расланган датасыннан алып 3 (өч) эш көненнəн дə соңга калмыйча, һəм, Исемлеккə үзгəрешлəр кертелгəн очракта, үзгəреш кертелгəн датадан алып 7 (җиде) эш көненнəн дə соңга калмыйча, төгəллəштерелгəн исемлекне Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дəүлəт хезмəткəрлəре департаментына һəм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягə каршы идарəсенə җибəрергə.

4. «Дəүлəт граждан хезмəте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2010 елның 23 ноябрендəге 395 номерлы боерыкны үз көчен югалткан дип танырга.

5. Əлеге боерыкның үтəлешен тикшереп торуны «Татмедиа» республика матбугат һəм массакүлəм коммуникациялəр агентлыгы җитəкчесе беренче урынбасары Ф.И. Шаһиəхмəтовка йөклəргə.

Җитəкче И.Д. Миңнəхмəтов

«Татмедиа» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы җитәкчесенең
2013 елны 15 августындагы
13-п/1 номерлы боерыгы белән
расланды

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында гражданнар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре аларны биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

| Т/с | Дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы | Вазыйфалар саны |
|---|---|---|
| 1. | Җитәкченең беренче урынбасары | 1 |
| 2. | Җитәкче урынбасары | 1 |